ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.11.2022 Казан ш. № 570-149/кс-2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында

«Технологик инженерлык системалары» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә хезмәт күрсәтү буенча эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыруны туктатуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 17 ноябрендәге 38-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Технологик инженерлык системалары» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм су агызуга 2021-2025 елларга тарифлар билгеләү хакында» 09.12.2020 №369-167/кс-2020;

«Технологик инженерлык системалары» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык су агызуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.12.2020 №369-167/кс-2020 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 елга төзәтмә кертү хакында» 27.10.2021 №182-13/кс-2021.

2. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев